**Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре**
**2022-2023 нче уку елы**
**10-11 нче сыйныф**

**Эш вакыты – 120 минут**
**Гомуми балл – 96**

**1. Конго Демократик Республикасы (ЗАИР) нинди ярымшарларда урнашкан?** *(2 БАЛЛ)*
1.Төньяк, көньяк, көнбатыш, көнчыгыш;
2.Төньяк, көньяк, көнчыгыш;
3.Төньяк, көнчыгыш, көнбатыш
4. Көньяк, көнчыгыш, көнбатыш.

**2. Атлантик океан һәм аның диңгезләре буена урнашкан дәүләтләр:** *(4 БАЛЛ)*
1. Болгария, Колумбия, Гвинея-Бисау;
2. Мальта, Мозамбик, Иордания;
3. Грузия, Багам, Мальдив;
4. Сирия, Азәрбайҗан, Тринидад һәм Табаго.

**3. Туры китерегез** *(4 БАЛЛ)*

| *Чиктәш дәүләтләр* | *Таулар* |
|---|---|
| 1. Испания һәм Франция | А. Карпат |
| 2. Польша һәм Словакия | Б. Һималай |
| 3. Һиндстан һәм Кытай | В. Анд |
| 4. Чили һәм Аргентина | Г. Пиреней. |

**4. Африкадагы кайсы монархияле дәүләт диңгез юлы белән тоташкан?***(4 БАЛЛ)*
1. Лесото
2. Мавритания
3. Марокко
4. Свазиленд

**5. Азия илләренең башкаласы булып саналалар:** *(2 БАЛЛ)*
1. Абу-Даби, Сана, Хартум;
2. Янгон, Шанхай, Исламабад;
3. Тхимпху, Куала-Лумпур, Манама;
4. Катманду, Лилонгве, Амман.

**6. Геотермаль энергия зур әһәмияткә ия булган ил:** *(2 БАЛЛ)*
1. Россия;
2. АКШ;
3. Ирландия;
4. Исландия.

**7. Туры китерегез** *(8 БАЛЛ).*

| *Чыганак* | *Ресурс төре* |
|---|---|
| 1. Итабира | А. Нефть |
| 2. Гавар | Б. Тимер рудасы |
| 3. Уйэпа | В. Бакыр рудасы |
| 4. Чукикамата | Г. Алюминий рудасы |

**8. Халык тыгызлыгы аз булган илләр** *(2 БАЛЛ).*

1. Оман, Парагвай, Бельгия;
2. Вьетнам, Лаос, Камбоджа;
3. США, Япония, Германия;
4. Россия, Ливия, Монголия.

**9. Иллэрне балалар туу саны арта бару тәртибендэ урнаштырыгыз.**
*(4 БАЛЛ).*

1. Һиндстан; 3. Кения;
2. Германия; 4. АКШ.

_____________________________________

**10. Иллэрне уртача тормыш озынлыгы кимү тәртибендә урнаштырыгыз**
*(4 БАЛЛ).*

1. Әфганстан 3. Германия
2. Япония 4. Кытай

_____________________________________

**11. Бер төрле милләтле дәүләтләр** *(2 БАЛЛ)*

1. АКШ, Канада, Австралия, Яңа Зеландия;
2. Исландия, Испания, Ирландия, Италия;
3. Япония, Дания, Филиппин, Швеция;
4. Португалия, Әрмәнстан, Норвегия, Корея Республикасы.

**12. Экспорт структурасында, нефть һәм нефть продуктларын читкә чыгару буенча 50% тан арткан дәүләтләр:** *(4 БАЛЛ).*

1. Катар, Алжир, Венесуэла;
2. Согуд Гарәбстаны, Индонезия, Бөекбриания;
3. АКШ, Габон, Кувейт;
4. Бруней, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Һиндстан.

**13. Нефтьне экспортлаучы һәм импортлаучы дәүләтләр бирелгән. Кайсы парда хата бар?**
*(4 БАЛЛ).*

1. Иран-Япония
2. Бразиля-АКШ
3. Алжир-Франция
4. Норвегия-Германия

**14. Дөрес җавапларны туры китерегез** *(4 БАЛЛ).*

| ***Бик зур йөк агышы юнәлешләре*** | ***Продукция*** |
|---|---|
| 1. Россия-Көнчыгыш Азия | А.Ташкүмер |
| 2. Фарсы култыгы – Көнбатыш Европа | Б. Нефть |
| 3. Австралия- Япония | В.Табигый газ |

**15. Зур нефть чыганакларының кайсы юнәлештә дөрес билгеләнгән булуын ачыклагыз:** *(10 БАЛЛ).*

1. Гавар (Африка), Серир (Америка) Прадхо-Бей (Европа); Экофиск (Азия);
2. Гавар (Азия), Серир (Африка), Прадхо-Бей (Америка), Экофиск (Европа);
3. Гавар (Америка), Серир (Европа), Прадхо-Бей (Азия), Экофиск (Америка);
4. Гавар (Европа), Серир (Азия), Прадхо-Бей (Африка), Экофиск (Америка);

**16. Тимер рудасы табу һәм корыч кою буенча алдынгылыр (лидерлар):** *(2 БАЛЛ).*

1. БДБ илләре;
2. Чит Европа илләре;
3. Төньяк Америка;
4. Чит Азия илләре.

**17. Америкада урнашкан әлеге илнең халкы 100 млн. нан артык. Рәсми телләре – испан, диннәре – католик. Әйдәүче тармак – авыл хуҗалыгы үсемлекчелеге. Ул барлык җитештерелгән продукциянең 60% ын тәшкил итә. Мамык, кофе, шикәр камышы үстерелә. Биредә вулканнар бик күп. Җир тетрәүләр дә еш була. Тропик кояшы да кыздыра. Аның башкаласы 2240м биеклектә, тау арасы казанлыгына урнашкан. Анда гомер-гомергә индеецлар яшәгәннәр. Бу кайсы ил һәм аның башкаласы ничек атала?** *(8 БАЛЛ)*

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**18. Бирелгән раслаулар Европа илләренең кайсыларына туры килә? Шул илләрнең исемнәрен языгыз.** *(10 БАЛЛ).*

1. Әлеге дәүләтнең бер дәүләт теле үзенең килеп чыгышы белән венгр теленә якын.
2. Илнең зур территорясе тигезлектән тора. Шул сәбәпле аның икътисадында (экономикасында) авыл хуҗалыгы әһәмиятле булып тора.
3. Дөньякүләм сәясәттә (политикада) әлеге ил нейтраль ил булып санала.
4. Кара металлургия әлеге илдә урта гасырда ук барлыкка килә.
5. Балык тоту буенча, әлеге ил Бөекбритания белән тискәре мөнәсәбәттә яши.

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**19. Бу океан бөтендөнья икътисадында (экономикасында) зур әһәмияткә ия, чөнки йөк ташулар, балык тотуның гаять зур өлеше әлеге океанга туры килә. Аны европалылардан беренче булып испанлы Васко Бальбоа 1513 елда күрә. Коры җирдән иң ерак урнашкан нокта да шушы океанда. Әлеге нокта Питкэрн утраулары яр буеннан һәм Антарктиданың Дарт борынынннан якынча 2670 км ераклыкта урнашкан. Океанда чоңгыллар да бик күп, аларның саны да утыздан арта. Суның тозлылыгы 35 промилле, уртача температура + 19 С градус. Иң югары температура экваториаль зонаның көнбатыш өлешендә + 27 – +29 С градус. Әлеге океанның исемен языгыз.** *(8 БАЛЛ).*

________________________________________________________________

**20. Австралия дәүләте башкаласы һәм төп үзәкләрнең дөрес урнашуын билгеләгез** *(8 БАЛЛ).*

1. Сидней башкаласы төп икътисадый үзәкләр булган Мельбурн һәм Аделаида арасында;
2. Канберра башкаласы төп икътисадый үзәкләр булган Мельбурн һәм Аделаида арасында;
3. Мельбурн башкаласы төп икътисадый үзәкләр булган Канберра һәм Брисбен арасында;
4. Канберра башкаласы төп икътисадый үзәкләр булган Аделаида һәм Брисбен арасында.